**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИБӘХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ КАРАРЫ**

**Өченче чакырылыш чираттан тыш утырыш**

**30 ноябрь 2018ел №111 Кече Кибәхуҗа авылы**

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә физик затлар милкенә салым турында”гы 2014 елның 21 ноябрендә (аендагы) 86 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, “Россия Федерациясе Салым кодексы 52 нче статьясенең беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында”гы 2018 елның 03 августындагы 334-ФЗ санлы Федераль законга туры китереп, Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Советы карар кабул итте,

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә физик затлар милкенә салым турында”гы 2014 елның 21 ноябрендә 86 санлы (2015 елның 18 маенда 102 санлы, 2015 елның 12 октябрендә 4 санлы, 2018 елның 12 апрелендә 83 санлы редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.түбәндәге эчтәлектәге 3.2 пункты өстәргә:

“3.2. Түбәндәге физик затларны милек салымыннан азат итәргә:

3.2.1. 18 яшькә кадәрле дүрт һәм аннан да күбрәк балалары булганнарны;

3.2.2 әлеге пунктның 3.2.1 пунктчасының күрсәтелгән гражданнарның балаларын;

3.2.3. тулы дәүләт тәэминатында булмаган инвалид балаларның ата-аналарын (уллыкка/кызлыкка алучылар, опекуннар, тәрбиягә алучылар).

Салымга ташламалар түбәндәге объектларга каралган:

1) фатир, фатирның бер өлеше яки бүлмә;

2) торак йорт яки торак йортның бер өлеше.

Салымга ташлама, салым түләүченең теләге буенча, гаилә карамагындагы бер генә объектка бирелә.

Салымга ташлама Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүченең милкендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлеге максатларында кулланылмаучы объект өчен тиешле салым күләмендә бирелә.

Салымга ташламага хокукы булган физик затлар салым органына салымга ташлама бирү турында гариза яза, шулай ук салым түләүченең салымга ташламага хокукын раслаучы документлар тапшыра ала.

Салымга ташламага хокукны раслаучы документлар булып әлеге төр салым түләүче физик затның шәхесен раслаучы документ, шулай ук аның исеменә бирелгән күп балалы гаилә таныклыгы, яки өч һәм аннан да күбрәк балаларның туу турындагы таныклыклары тора.

Салымга ташламалы объектны сайлавы турында салым түләүче салым органына салым чоры булган елның 1 ноябренә кадәр хәбәр итәргә тиеш. Шушы вакыттан күрсәтелгән объектларга салымга ташлама кулланыла башлый.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәренең Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Карарның 1 пунктында күрсәтелгән 3.2 пункты рәсми бастырып чыгарганнан соң бер ай үткәч көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан гамәлдәге хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

Авыл җирлеге Башлыгы И.Г.Заһидуллин